
# *Фәнис Яруллин*



Татарстанның халык шагыйре,
Г. Тукай һәм М. Җәлил исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре”, Халыклар дуслыгы ордены кавалеры.

# Тормыш юлы

- Фәнис Гатаулла улы Яруллин 1938 елның 9 февралендә Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылында туа. Җидееллык белемне туган авылында ала, сигезенче сыйныфны Баулыда тәмамлый. 1954 елда “Татнефть” берләшмәсенең Баулы элемтә оешмасында монтёр булып эшли башлый. 1957 елда гаскәри хезмәткә алына. Фәнис Яруллин армиядә һава укчы-радистлары мәктәбендә укый, шунда спорт белән мавыга. Бәхетсезлеккә каршы, спорт күнегүләренең берсендә, турниктан егылып төшеп, умыртка сөяген имгәтә һәм гомергә йөри алмас хәлдә кала.1963 елда экстерн тәртибендә урта белем ала, 1970 елда читтән торып укып, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Уку һәм озакка сузылган дәвалану белән бергә ул шигырьләр, проза һәм драма әсәрләре иҗат итә.

# Фәнис Яруллинның иҗади эшчәнлеге.

- Ул шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, әкиятләр остасы һәм ялкынлы публицист та. Иҗатының кайсы ягын гына алып карама, аның дөньяга яшәешкә үзенә генә хас  мөнәсәбәтен күрәсең.
- “Мин тормышка гашыйк”, “Җилкәннәр җилдә сынала”, “Әнә килә автомобиль”, “Һәркемнең үз сукмагы” һәм башка шигырь, проза, сәхнә әсәрләре яза



# ТУГАН ЯГЫ КИРӘК КЕШЕГӘ



Читтә йөргән чакта, сагындырып,

Керер өчен төнлә төшенә,

Зәңгәр таңлы, биек аяз күкле

Туган ягы кирәк кешегә.

Зур уңышлар яулап, заманалар

Матур бәя бирсә эшенә, —

Шатлыкларын ишеттерер өчен

Туган ягы кирәк кешегә


Фәнис
ЯРУЛЛИН
Һау бул, һөйөү!


ФӘНИС ЯРУЛЛИН
Урман кызы



# Шагыйрь үзе турында

- Февраль аенда тугангамы, канымда — февраль бураннарының уйнаклыгы, күңелемдә — Өемташ тауларының горурлыгы, җанымда — Ык елгасының ярсуы, хисләремдә — әрәмә чәчәкләренең назы, холкымда — дала җилләренең үҗәтлеге, тәнемдә тау имәннәренең ныклыгы бар. Табигатемдә булган шушы сыйфатлар кояшны каплаган кара болытлар аша йолдызлы күкләрне күрергә, салкыннарда сулышым белән җылытып учларымда гөлләр үстерергә, кешеләр гамен үз гамьнәремнән өстен куярга мөмкинлек бирде.



# Ф.Яруллинның тормыш девизы



“Нинди генә очракларда да кеше булып кала алу һәм намуска тап төшермәү.”

Кеше дигән
бөек исемне
гел
Йөрттең Син
горур күтәреп.
Яшәмәдең
юкны бушка
иләп,
Бер дә юкка
гомер үткәреп.

